ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.03.2023ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 825**

«Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт өчен түләү исәпләнә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2021 елның 7 декабрендәге 3127 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт өчен түләү исәпләнелә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 13 сентябрендәге 987 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт өчен түләү исәпләнә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2021 елның 7 декабрендәге 3127 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта).
2. Әлеге карар 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында ((http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 24 мартындагы
825 номерлы карарына
кушымта

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 15 279 |
| 2 | 1,0159 | 15 522 |
| 3 | 1,0323 | 15 773 |
| 4 | 1,0480 | 16 012 |
| 5 | 1,0656 | 16 281 |
| 6 | 1,0827 | 16 543 |
| 7 | 1,1010 | 16 822 |
| 8 | 1,1187 | 17 093 |
| 9 | 1,1363 | 17 362 |
| 10 | 1,1553 | 17 652 |
| 11 | 1,1736 | 17 931 |
| 12 | 1,1933 | 18 232 |
| 13 | 1,2129 | 18 532 |
| 14 | 1,2325 | 18 831 |
| 15 | 1,2528 | 19 142 |
| 16 | 1,2738 | 19 462 |
| 17 | 1,2947 | 19 782 |
| 18 | 1,3163 | 20 112 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 – 2 разрядка түбәнрәк итеп билгеләнә